**Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге**
**Башкарма комитеты**
**карары**

**№11212**
**16.11.2023**

Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5773 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

Шәһәр Уставы, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасы турында» 2022 елның 25 октябрендәге 5773 номерлы Карарына (Башкарма комитетның 2023 елның 31 мартындагы 2595 номерлы Карары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Башкарма комитетның финанс идарәсенә муниципаль программа чараларын финанслауны Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджетында «Халыкны социаль тәэмин итү» 1003 бүлеге буенча каралган акчалар хисабына 510 883,12 мең сум: 2023 ел – 222 560,93 мең сум; 2024 ел – 141 994,75 мең сум; 2025 ел – 146 327,44 мең сум күләмендә тәэмин итәргә.»;

2) 2023-2025 елларга Яр Чаллы шәһәре халкына адреслы социаль ярдәм күрсәтү муниципаль программасында:

- 1 бүлектә «Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| Еллар буенча бүлеп, программаны финанслау күләме һәм чыганаклары | Финанслау чыганаклары | Программаны тормышка ашыру еллары | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | 2023 ел (мең сум) | 2024 ел (мең сум) | 2025 ел (мең сум) | Тормышка ашыру чорына барлыгы (мең сум) |
| | Муниципаль бюджет | 222 560,93 | 141 994,75 | 146 327,44 | 510 883,12 |
| | Федераль бюджет | - | - | - | - |
| | Республика бюджеты | - | - | - | - |
| | Башка чыганаклар | - | - | - | - |

- 4 бүлекне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4 бүлек. Программаны ресурслар белән тәэмин итү

2023-2025 елларга программаны финанслау күләме 510 883,12 мең сум тәшкил итә.

Программаны финанслау чыганагы булып Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге бюджеты тора.

Чор өчен барлыгы 510 883,12 мең сум, шул исәптән Программаны тормышка ашыру еллары буенча:

2023 ел – 222 560,93 мең сум;

2024 елга – 141 994,75 мең сум;

2025 елга – 146 327,44 мең сум.»;

- 6 бүлектә:

10 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «10. | Мактаулы гражданнарны, Татарстан Республикасы һәм Яр Чаллы шәһәре үсешенә зур өлеш керткән гражданнарны, махсус хәрби операциядә катнашучыларны җирләү чарасы | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре, Башкарма комитет | Ел дәвамында | Кеше саны | 1 | 2 | 2 | 2 | 160,00 | 20,00 | 20,00»; |

23 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «23. | Инвалид өчен тышкы пандус урнаштыру | Башкарма комитетның районнар хакимиятләре | Ел дәвамында | Кеше саны | 0 | 1 | 0 | 0 | 1 512,7 | 0 | 0»; |

29 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| «29. | Инвалид балаларны, сәламәтлеге буенча мөмкинлекләре чикле балаларны, муниципаль белем бирү оешмаларында укучы 3 һәм аннан күбрәк балигъ булмаган балалары булган гаиләләрдә тәрбияләнүче балаларны түләүсез кайнар ризык белән тәэмин итү | Башкарма комитет | Ел дәвамында | Балалар саны | 6404 | 7300 | 7300 | 7300 | 124000,00 | 41607,42 | 43271,71»; |

«барлыгы» юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | | | | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | «барлыгы: | | | | 79606 | 116922 | 116971 | 116971 | 222560,93 | 141994,75 | 146327,44»; |

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары Р.М. Хәлимовка, Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага йөкләргә.

Башкарма комитет Җитәкчесе
вазыйфаларын башкаручы И.С. Зуев